**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.05.2026 г. Казань № 54од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында» 2023 елның 7 сентябрендәге 125од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә **боерам:**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында» 2023 елның 7 сентябрендәге 125од номерлы боерыгына (2023 елның 9 ноябрендәге 161од номерлы, 2024 елның 7 июнендәге 78од номерлы, 2024 елның 28 августындагы 150од номерлы, 2025 елның 21 февралендәге 19од номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 55од номерлы, 2025 елның 30 декабрендәге 162од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәнең (алга таба - Нигезләмә) 2.1 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә, Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.»;

Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең, норматив хокукый актларны теркәү һәм хокукый тәэмин итү бүлегенең, Министрлыкның министр билгеләгән башка бүлекчәләренең дәүләт хезмәткәрләре;»;

Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт граждан хезмәткәренең Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне тапшыруы;»;

Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3.11 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмә нигезендә дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;»;

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
2023 елның 7 сентябрендәге
125од номерлы боерыгы
белән расланган
(2026 елның 5
маендагы 54од
номерлы боерык
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Гомзик<br>Илья Александрович | министрның беренче урынбасары, Комиссия рәисе; |
| Низамиев<br>Марат Фәрит улы | министр урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары; |
| Леонидова<br>Виктория Игоревна | кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы әйдәп баручы консультанты, Комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Боровков<br>Максим Сергеевич | министр урынбасары; |
| Закирова<br>Аида Альберт кызы | финанс бүлеге башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының беренчел профсоюз оешмасы рәисе; |
| Ибәтов<br>Мөхәррәм Мансур улы | министр урынбасары;; |
| Латыева<br>Татьяна Юрьевна | кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы; |
| Музеев<br>Александр Олегович | “Россия юристлары ассоциациясе” Татарстан төбәк бүлеге аппараты җитәкчесе - башкарма директорның беренче урынбасары (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Нигъмәтҗанов<br>Алмаз Альберт улы | “Казан (Идел буе) федераль университеты” югары белем бирү ФДАМУ юридик факультетының конституциячел һәм административ хокук кафедрасы доценты (килешү буенча); |
| Слепнева<br>Эльмира Илсур кызы | норматив хокукый актларны теркәү һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы; |
| Өметбаев<br>Ренат Камил улы | Татарстан Республикасы Рәисе идарәсенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге баш киңәшчесе (килешү буенча); |
| Хөрмәтуллина<br>Алсу Мәхмүт<br>кызы | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, юридик фәннәр кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты юридик факультетының конституциячел һәм административ хокук кафедрасы доценты (килешү буенча). |